УДК 792

*Ш.А. Абдурасулов*

# ҮЗБӘКСТАН ТЕАТРЛАРЫНДА ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ СӘХНӘ ИНТЕРПРЕТАЦИЯСЕ

В статье проанализированы влияние творчества знаменитого киргизского писателя Чингиза Айтматова на узбекское сценическое искусство, идейно-художественные особенности спектаклей, поставленных в театрах Узбекистана по мотивам творчества писателя. Автор рассматривает степень воздействия прозы Ч. Айтматова на обновление форм и стилей в узбекской режиссуре, актерском и сценографическом искусствах, на развитие жанров драмы и музыкальной драмы, формирование репертуара театров. В статье также идет речь об особенностях и критериях инсценировки прозаических произведений на примере творчества Чингиза Айтматова.

**Ключевые слова:** Чингиз Айтматов, инсценировка, проза, режиссерская интерпретация, музыкальная драма, легенда, жанр, повесть, сценография, актерское исполнение

This article analyzes the influence of the renowned Kyrgyz writer Chingiz Aitmatov on Uzbek performing arts and the ideological and artistic characteristics of performances based on the writer's works staged in Uzbek theaters. The author examines the influence of Chingiz Aitmatov's prose on the renewal of forms and styles in Uzbek directing, acting, and scenography, the development of drama and musical drama, and the formation of theater repertoires. The article also discusses the characteristics and criteria for staging prose works, using Chingiz Aitmatov's work as an example.

**Keywords:** Chingiz Aitmatov, staging, prose, director's interpretation, musical drama, legend, genre, novella, scenography, acting

Иҗаты гомумкешелек мирасы хәзинәсенә кергән Чыңгыз Айтматов бөтен дөньяда сәнгатьчә фикерләү үсешенә сизелерлек йогынты ясый. Әдипнең тар милләт кысаларында гына калмавы һәм кешелек проблемаларын фәлсәфи яктан аңлавы, космик масштабта кеше һәм чорның, шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтләрен, идеаль дөнья белән түбән догматлар арасындагы мәңгелек көрәшне чагылдыруы Айтматов феноменын билгеләүче фактор булып тора. Шуңа күрә язучының әсәрләре миллионлаган укучыларның йөрәкләрендә яңгыраш тапты, дөньяның йөзләгән телләренә тәрҗемә ителде, һәм бу процесс бүгенге көндә дә туктамый.

Әдип үзенең әсәрләрендә халык хәтерендә яшәүче борынгы хикәятләрне, мифларны, легендаларны нәтиҗәле файдалана, тормышчан һәм уйлап чыгарылган сюжет линияләрен оста итеп синтезлый. Легендаларның символик образлары әдипнең фәлсәфи карашларын

гына чагылдырып калмый, бәлки әсәрләренең сәнгатьчә дөньясын, поэтикасын, драматизмын да билгели.

Чыңгыз Айтматов кебек зур язучының иҗат диапазоны әдәбият өлкәсе белән генә чикләнми. Аның әсәрләренә нигезләнеп спектакльләр куела, кинофильмнар төшерелә, картиналар языла, алар мәдәни тормышның башка өлкәләрендә дә чагылыш таба, димәк, аларны сәнгать белеме күзлегеннән дә өйрәнергә кирәк. Язучының повесть һәм романнарын бик күп илләрнең театрлары сәхнәләштергән, алар театр әһелләре өчен бетмәс-төкәнмәс чыганак һәм бай материал булып хезмәт иткәннәр һәм итәләр. Символларга нигезләнгән фәлсәфи образлар, көчле характерлы геройлар, социаль каршылыкларга таянган драматизм театр сәнгатенең табигатенә якын, шуңа күрә алар сәнгать ягыннан җитлеккән сәхнә әсәрләренең нигезенә ята.

Чыңгыз Айтматов әсәрләре буенча куелган спектакльләр Россиянең күп кенә театрларында һәм язучының туган җирендә зур уңыш белән бара. Әлбәттә, һәр спектакльдә актёрлык сәнгатенә хас милли үзенчәлекләр ярылып ята [9: 209].

Чыңгыз Айтматов әсәрләренең сәхнә интерпретациясенә багышланган бик күп тикшеренүләр үткәрелгән. Алар арасында Джукун Иманкуловның «Айтматов и советский многонациональный театр» дигән докторлык диссертациясен һәм «Искусство театра: Произведения Чингиза Айтматова на сценах театров республик Средней Азии и Казахстана» дигән монографиясен аерым билгеләп үтәргә кирәк [4; 5]. Автор Чыңгыз Айтматов әсәрләре мотивлары буенча Кыргызстан, Казахстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан һәм өлешчә Үзбәкстан театрларында куелган спектакльләрне анализлый.

«Театр Айтматова – это мир крупных социальных проблем, глубоких чувств и больших идей, нередко общая тональность этого мира носит трагедийный характер. В нем отражены лучшие образцы мировой художественной культуры – от Древнего Востока и античного мира до наших дней» [4: 4], – ди автор. Спектакльләрне әзерләү барышында режиссёрның образлы фикерләве, актёрның интуитив акылы үсә, барлык сәхнә осталарының индивидуальлеккә омтылышы көчәя. Д. Иманкулов фикеренчә, «Конфликты у Айтматова остры, характеры сильны, природа одухотворена, и театр передает все это зрителю, оказывая влияние не только на его разум, но и на чувства, поскольку театральное искусство, прежде всего эмоциональное» [4: 8]. Айтматов әсәрләренең вакыты һәм киңлеге чикләнмәгән, алар төрле чорлардагы карашларга аваздаш, теләсә кайсы заманның көнүзәк идеяләре өчен трибуна булып хезмәт итә алалар.

Әлеге тикшеренүдә тасвирлау, классификация, чагыштырма анализ, әңгәмә, күзәтү, комплекслы якын килү, индукция, дедукция методлары кулланыла. Чыңгыз Айтматов әсәрләре буенча куелган спектакльләр тематик һәм жанр үзенчәлекләреннән чыгып классификацияләнә һәм аларның сәнгать-идея үзенчәлегенә анализ ясала.

Проза әсәрләрен, әдәби һәм драматик текстларны инсценировкалауның теоретик нигезләрен ачканда, күп кенә чит ил әдәбият һәм сәнгать теоретикларының фәнни хезмәтләре һәм анализ методлары өйрәнелә. Бу планда танылган итальян әдәбият белгече һәм философы Умберто Эконың семиотик анализ методы зур әһәмияткә ия. Инсценировкалау процессын тикшергәндә, әлеге фәнни-теоретик метод мөһим объект ролен үти. Шулай ук тикшеренүнең методологик нигезен билгеләгәндә Р. Барт, М. Бахтин, Г. Бояджиев, В. Белинский, В. Волькенштейн, А. Луначарский, К. Рудницкий, Н. Скороход, В. Шкловский кебек теоретикларның фәнни хезмәтләренә таяналар.

Үзбәкстан Республикасы Президенты Шәүкәт Мирзиеевның 2018 елның 2 апрелендәге «Бөек язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Чыңгыз Айтматовның 90 еллыгын киң күләмдә бәйрәм итү турында» Указы нигезендә республиканың күп кенә театрларында язучының әсәрләре буенча спектакльләр куела. Бу процесста мәкалә авторы үзе дә катнаша, һәм спектакльләрне алдан карап, премьералар вакытында үз тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен әйтә. Ул матбугатта спектакльләргә багышланган рецензия һәм мәкаләләрен бастыра, шулай ук театр сәнгатенә багышланган түгәрәк өстәлләрдә һәм фәнни семинарларда докладлар белән чыгыш ясый.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, Чыңгыз Айтматов иҗаты тугандаш халыклар театрлары, аерым алганда үзбәк театры үсешенә сизелерлек йогынты ясый, театр сәнгатенең төрле юнәлешләре һәм жанрлары формалашуда мөһим чыганак булып тора. Бу, үз чиратында, язучының иҗатын театр белеме ракурсында өйрәнү зарурлыгын ассызыклый. Тикшеренүдә чагылыш тапкан фикерләр һәм нәтиҗәләрне драматурглар, театр белгечләре, актёрлар һәм әлеге юнәлештәге уку йортлары студентлары фәнни-методик ярдәмлек сыйфатында куллана алалар. Шулай ук тикшеренүдә алга сөрелгән теоретик фикерләрне турыдан-туры гамәлдә, ягъни проза әсәрләре мотивлары буенча спектакльләрне сәхнәләштерү процессында кулланып була.

Чыңгыз Айтматов иҗаты үзбәк театры тарихының да үзенчәлекле сәхифәсен тәшкил итә. Әдипнең мәшһүр повесть һәм романнары илебез театрларында күп тапкырлар сәхнәләштерелә, режиссёр һәм актёрларга иҗади үсәргә, гаҗәеп символ һәм экспериментларны популярлаштырырга ярдәм итә, поэтика һәм нәфис сәхнә дөньясын үстерә.

Язучының әсәрләрен сәхнәләштерүдә беренче тәҗрибә танылган режиссёр Ташхужа Хожаев тарафыннан 1964 елда гамәлгә ашырыла. Шагыйрь һәм драматург Хамид Гулом тәрҗемәсенә нигезләнеп куелган «Сарвкомат дилбәрим» («Кызыл яулыклы гүзәлкәем») спектакле лирик-драматик формада яшь йөрәкләргә хас булган дәртне, матур, эчкерсез, саф мәхәббәт хисләрен тапшыра, шуның белән тамашачыларга аерым бер эстетик ләззәт бирә.

Мәгълүм булганча, «Сарвкомат дилбәрим» повесте – романтик әсәр, бай шигъри телле һәм лиризм белән тулы, ике яшь кешенең

матур һәм драматик мәхәббәтен тасвирлый. Повестьны сәхнәләштергәндә әсәрнең нәкъ менә шушы үзенчәлекләренә һәм эмоциональ колоритны саклауга һичшиксез игътибар итәргә кирәк була. Прозаны сәхнәгә күчергәндә барысы да шома гына бармый. Н. Заһидова фикеренчә, «Автор инсценировки А. Котельников, пытаясь сконцентрировать события повести и втиснуть их в жанр драматической комедии, не сумел передать лаконичную поэтичность, свойственную писательской манере Ч. Айтматова. В инсценировке много раздробленных эпизодов, притом часть из них не работает на основную идею произведения» [3: 88–89]. Инсценировкадагы кимчелекләргә режиссёрның интерпретациясе һәм актёрларның рольләрне оста итеп башкаруы ярдәмендә билгеле бер дәрәҗәдә чик куела.

Спектакльдә Ильяс образын Тургун Азизов башкара. Актёрның кичерешләрне, яшьлектәге хисләрнең сафлыгын дөрес һәм тулы итеп җиткерә белүе, лирик-драматик осталыгы тамашачыларда яхшы тәэсир калдыра.

Повестьта төп героиняларның берсе булган Әсәл образы вакыйгалар үсешендә мөһим урын алып тора. Аның хисләре турыдан-туры түгел, ә башка образлар, башка геройларның сүз һәм гамәлләре аша тапшырыла [1: 89]. Әсәл ролен театрның ике талантлы актрисасы – Ирода Алиева һәм Ойдин Норбоева башкара. Икесе дә, үзләренең башкару манераларыннан чыгып, образны төрлечә интерпретацияләр. Ирода Алиеваның Әсәле лирик кичерешләргә бирелүчәнлеге, төрле эмоциональ төсләргә бай булуы белән игътибарны җәлеп итсә, Ойдин Норбоеваның героинясы пафос дәрәҗәсендәге югары драматизмы белән аерылып тора.

Бу әсәр 1978 елда Мукими исемендәге Музыкаль драма театрында «Қизил дуррали нозик ниҳолим» («Кызыл яулыклы нәфис агач») исеме белән куела. Драматург Хамид Гулом, режиссёр Абдрашид Рахимов һәм театр труппасы, әсәрнең шигъри эчтәлеген тирән тоеп, аның лирик интонацияләрен, музыкаль драма жанрындагы сәнгати үзенчәлекләрен ачалар.

Әсәл образын актриса Наимә Пулатова башкара. Ягымлы тавышы, кайгы һәм сагыш тулы арияләре, вокал һәм драматик мөмкинлекләре ярдәмендә актриса героиняның характерын, образның асылын менә дигән итеп ача.

Милли театр интерпретациясендә төп игътибар повестьтагы драматизмга, геройларның эчке каршылыкларына бирелсә, Мукими исемендәге театрда төп урынны әсәрнең лирик яңгырашын, шигъри мотивларын тапшыру ала.

1965 елда Мукими исемендәге музыкаль драма театры коллективы язучының «Ана кыры» повестен сәхнәгә куя. Инсценировканың авторы – шагыйрь Тураб Тула. Режиссёр Абдрашид Рахимов, композитор Ильяс Акбаров повестьның поэтикасын, аның җылысын музыка теленә күчерәләр.

Төп героиня Тулганай ролен дәртле һәм пафослы манерада Турсунхон Жафарова башкара. Сугышның барлык куркынычларын һәм авыр һөҗүмнәрен кичергән көчле хатын-кыз характеры һәм аның эчке кичерешләре спектакльнең төп идеясен билгели. Айтматов повесте белән чагыштырганда, музыкаль драмада образлар беркадәр үзгәреш кичерә. Алиман төп катнашучы була. Спектакльнең берданбер фигурасы булмаса да, Тулганай да үзенең әһәмиятле урынын саклый [6: 98].

Белгечләр билгеләп үтүенчә, язучының теле һәм сөйләү стиле музыкальлеге белән аерылып тора. Чыннан да, Ч. Айтматов повестьларын укыганда укучының күңелендә музыка яңгырый. Нәкъ менә шушы үзенчәлек Айтматов прозасының музыкаль драма жанрына якын булуын күрсәтә. Әдәби әсәрнең эчтәлеген музыка аша кабул итү прозаның йогынты чикләрен киңәйтә [10: 281].

1979 елда Сурхандәрья өлкә музыкаль драма театры сәхнәсендә режиссёр Мансур Равшанов «Ана кыры» повесте буенча спектакль куя (инсценировка авторлары – О. Хожимуродов, С. Курбонкиличев). Режиссёр әсәрнең колоритын, рухын саклап, спектакльне театр таләпләренә туры китереп иҗат итә. Актриса Гулнора Равшанова башкаруында Тулганай образы үзендә милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен гәүдәләндергән, бөтен күңеле сугышка нәфрәт хисе белән тулган һәм үзендә кешелекнең әрнүен һәм кайгы-хәсрәтен чагылдырган хатын-кыз символы буларак ачыла.

Чыңгыз Айтматовны дөньякүләм таныткан «Ак пароход» повесте илебезнең берничә театрында сәхнәләштерелгән. Шунысы мөһим: аның һәрбер куелышы үзенчәлекле. Барыннан да элек, әсәрне сәхнәләштергәндә аның жанрын исәпкә алырга кирәк. В. Воронов «Ак пароход»ның жанрын повесть-гыйбрәтле хикәя дип билгели [2: 186]. Бу билгеләмә нигезсез түгел. «Ак пароход» чиста реалистик повесть түгел, анда чынбарлык фантазия белән үрелеп бара.

1983 елда «Ак пароход» Яшь тамашачылар театры сәхнәсендә режиссёр Махкам Мөхәммәдов тарафыннан куела. Премьерада Чыңгыз Айтматов үзе дә катнаша һәм спектакльдән соң аны иҗат итүчеләр белән әңгәмә кора.

Режиссёр, повестьның фәлсәфи эчтәлегенә үтеп кереп, күңелләрне нечкәртерлек, колоритлы, символларга һәм читләтеп әйтүләргә бай, формасы белән кызыклы спектакль иҗат итә. Үзәк герой – малай ролен башкарган актриса Едгора Зиемухамедова чын мәгънәсендә спектакльнең камертонына әверелә: кайчак күңелле, кайчак моңсу карашы, яңгыравыклы һәм сагыш тулы тавышы, тәэсирле паузалары белән тамашачыларның исендә кала.

Билгеле булганча, повестьта малайның хыялындагы ике әкият төп низагка нигез әзерли. Бу әкиятләрнең беренчесе – ак пароход турындагы хикәя – аның хыял җимеше, икенчесе – ана болан турындагы гыйбрәтле хикәяне бабасыннан ишетүе. Режиссёр, ана боланның символик образ булуыннан чыгып, аның кыяфәтен сәхнәдә шартлы

рәвештә күрсәтә: аның мәһабәт күләгәсе пәрдәгә чыгарыла, һәм ул яктылык ярдәмендә хәрәкәткә китерелә.

Аннары «Ак пароход» повесте Сурхандәрья өлкә музыкаль драма театры сәхнәсендә режиссёр Неъмат Пардаев тарафыннан куела (инсценировка авторлары – О. Хожимуродов, С. Курбонкиличев). Бу спектакльнең үзенчәлеге – төп игътибарның әсәрнең социаль-фаҗигалы эчтәлеген ачуга юнәлтелүендә. Режиссёр спектакльдә ана боланны үтерү аша деградацияләнгән җәмгыятьнең барлык кимчелекләрен һәм мәкерләрен фаш итә.

Спектакльнең идеясен һәм режиссёрның фикерләрен тамашачыга җиткерүдә рәссам Виктор Михайличенко сценографиясе аеруча әһәмиятле роль уйный. Агач койма белән әйләндереп алынган мәйдан рәвешендәге сәхнә декорациясе сарыклар утарын хәтерләтә. Спектакльнең финалында бу утарны ялкын чолгап ала, һәм малайның газаплануына һәм үлеменә сәбәп булган барлык түбәнлекләр, мәкер, явыз ниятләр янып көлгә әйләнә, дигән фикер үткәрелә.

Чыңгыз Айтматов әсәрләрен сәхнәләштерүнең чираттагы тәҗрибәсе 1986 елда Хәмзә исемендәге театрда (хәзер Үзбәк милли академия драма театры) режиссёр Рустам Хамидов тарафыннан тормышка ашырыла. Театр сәхнәсендә язучының «Гасырдан да озын көн» романы буенча спектакль куела.

Режиссёр Р. Хамидов бөтен игътибарын романның төп герое Идегәй язмышы белән бәйле вакыйгаларга юнәлтә. Спектакльне кую өчен Казахстан режиссёры А. Мамбетов[1] инсценировкасы алына.

Спектакльнең идеясен тапшыруда хәлиткеч рольне Буранлы Идегәйне гаять оста башкарган Зикир Мухаммаджонов уйный. Актёр трактовкасында Идегәй сабыр, ихтыяр көченә ия, тугрылыклы, вөҗдан кушканга гына буйсынучы, тирә-юньдәге кешеләр турында уйлаучы, аларның кайгы-хәсрәтләре белән яшәүче кеше итеп күрсәтелә. Бу образның көче, аның үзенчәлеге шунда ки, ул тирә-юньдәге вакыйгаларга үзенең дә катнашы бар дип хис итә һәм тормышка зур җаваплылык белән карый [8: 210].

Спектакльнең сценографиясе шулай ук үзенчәлекле булуы, катлаулы төзелеше белән аерылып тора. Авансцена өстенә күтәрелгән поезд рельслары һәм алар астында әйләнә торган шар вакыйгаларның Җир шары өстендә баруын күрсәтә. Сәхнә артыннан килгән поезд тавышы Идегәй язмышындагы биеклекләр һәм түбән тәгәрәүләр белән тулы озын юлга ишарә кебек яңгырый.

Билгеле булганча, манкорт турындагы легенда романда төп эпизодларның берсе булып тора. Виктор Левченко билгеләп үткәнчә, «В легенде Айтматов остается самим собой, он опирается на ту реальность, которая вошла в него с молоком матери; ее не нужно изобретать, расцвечивать и разукрашивать, – краски невольно про-

[1] А. Мамбетов М. Ауэзов исемендәге Казах Академия драма театры сәхнәсендә Чыңгыз Айтматовның байтак әсәрләрен куя һәм зур сәхнәләштерү тәҗрибәсенә ия була.

ступают изнутри» [7: 199]. Спектакльне иҗат итүчеләр манкорт турындагы легендага аерым игътибар бирәләр. Манкорт ролен Едгор Саъдиев, газап чигүче Найман Ананы – Сара Эшонтураева башкара. Бу гаять тәэсирле күренеш хәтереңне, асылыңны югалтуның коточкыч картинасын ача һәм бу фаҗига бөтен кешелек дөньясына кагыла.

Алга таба да Чыңгыз Айтматов әсәрләрен Үзбәкстан театрлары сәхнәләрендә кую юнәлешендә иҗади эзләнүләр дәвам итә. Мондый тәҗрибәләрнең иң уңышлысы 1999 елда Карши шәһәренең «Иске мәчет» театр-студиясе сәхнәсендә Таҗикстанның халык артисты, режиссёр Фаррух Касимов куйган «Найман она нидоси» («Ана чакыруы») спектакле була. «Гасырдан да озын көн» романындагы манкорт турындагы легенда нигезендә иҗат ителгән спектакль үзенең гадәти булмаган формасы, фәлсәфи чишелеше, символик элементлары белән сокландыра.

Режиссёр, нигездә, пластика, бию, музыка, җыр, хәрәкәт, актёрлар мимикасы кебек чараларны эшкә җигә. Динамик мизансценалар да драматизмны көчәйтүгә хезмәт итә.

Спектакль якты һәм тыныч тормыш картинасын чагылдырган күренештән башлана. Сәхнә уртасында май атлагыч тора, Жуламон (актёр Исок Тураев) шуның белән май яза, егет үзенең шатлык белән тулы яшьлегеннән ләззәтләнә. Бу тыныч тормышны бәреп кергән басып алучылар боза. Алар Жуламонны анасының кочагыннан тартып алалар, бәйлиләр һәм алып китәләр.

Жуламонны төрлечә җәзалыйлар, башына дөя тиресе кидерәләр, нәтиҗәдә егет үзенең асылын, хәтерен югалта. Ул бернәрсә дә хәтерләми торган, кеше үтерергә, җимерергә генә сәләтле рәхимсез бер хайвани затка әверелә. Баштарак саф ниятләрне чагылдырган май атлагыч манкортлар табынган яшәү урынына әверелә.

Жуламон ролен башкарган актёр Исок Тураев аның катлаулы халәтен, рухи киеренкелеген, хәтерсезлеген оста итеп күрсәтә. Актёрның күз карашы, хәрәкәтләре манкорт фаҗигасын бөтен тулылыгында чагылдыра.

Манкортның анасы Найман Ана – спектакльдә үзәк образларның берсе. Үзбәкстанның атказанган артисткасы Ойгул Халилова башкаруындагы трагик җырлар, моңсу бишек җырлары бичара ананың яралы җанын һәм газапларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. «Найман она нидоси» спектакле 1999 елда Бишкәк шәһәрендә уздырылган Чыңгыз Айтматов әсәрләре буенча куелган спектакльләрнең абруйлы театр фестивалендәге төп призга – гран-прига ия була.

Үзбәкстан Республикасы Президентының 2018 елның 2 апрелендәге «Бөек язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулуны киң күләмдә бәйрәм итү турында» карары театр коллективлары өчен дә бик мөһим була. Кыргыз язучысы әсәрләре мотивлары буенча спектакльләр булдыру бурычын күп кенә театрлар зур энтузиазм белән кабул итәләр.

Аерым алганда, «Ак пароход» повесте илнең ике театры сәхнәсендә куела – Үзбәк милли академия драма театрында (режиссёры Абубакр Рахимов) һәм Кашкадәрья өлкә музыкаль драма театрында (режиссёры Аскар Холмуминов).

Ике режиссёрның да повестька үз интерпретацияләре бар. А. Рахимов рәссам Б. Тураев белән бергә Иссык-Күл төбәгенең матур табигатен сурәтләгән образлы чишелеш таба. Ә Кашкадәрья театрында яшь режиссёр Аскар Холмуминов әсәрнең социаль-фәлсәфи эчтәлеген, трагик рухын ачарга омтыла. Шуңа күрә бу спектакльдә драматизм, психологизм өстенлек итә. Бигрәк тә яшь актёр Сухроб Исомовның (малай ролендә) Үзбәкстанның халык артисты Эркин Комилов (Мумин карт) белән уңышлы иҗади тандемын билгеләп үтәргә кирәк. Бу ике актёр сәхнәдә чын бабай белән оныкка әверелә, алар берберсен күз карашыннан аңлый, араларында рухи бердәмлек, якынлык булуы сизелә.

Язучының юбилее уңаеннан Мукими исемендәге Музыкаль драма театрында «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» (режиссёры М. Азизов), Үзбәкстан дәүләт драма театрында «Җәмилә» (режиссёры Г. Мәрдонов), Сырдәрья өлкә музыкаль драма театрында «Ана кыры» (режиссёры Н. Гойибназарова), Бердах исемендәге Каракалпак дәүләт музыкаль драма театрында «Лувр үрдәге» (режиссёры М. Реймов) кебек спектакльләр куела.

Нәтиҗә ясап, шуны да әйтергә кирәк: Чыңгыз Айтматов әсәрләре театр өчен бай чыганак булып хезмәт иткән һәм хәзер дә аларга игътибар зур. Моны үзбәк театр сәнгате мисалында ачык күрергә мөмкин. Прозаикның әсәрләре һәрвакыт сәхнә осталарының игътибар үзәгендә була, чөнки алар бай социаль-фәлсәфи эчтәлеккә ия, символик образлар белән тулы, гомумкешелек мәгънәсе белән сугарылган борынгы легенда һәм мифларга нигезләнә.

Чыңгыз Айтматов әсәрләренең Үзбәкстан театрларында куелышын анализлау түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә:

– язучы әсәрләре мотивлары буенча республика театрларында музыкаль драма жанрында күп кенә спектакльләр («Кызыл яулыклы гүзәлкәем», «Ана кыры») куела. Аның прозасының шигърилеге, лириклыгы аркасында сәнгатьчә чаралар, музыкаль театр стиле байый;

– язучының прозасы үзбәк театр сәнгатендә символик театр формалашуга билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясый («Ак пароход», «Диңгез ярын иңли ала эт»);

– әдипнең иҗаты социаль-психологик пландагы сәхнә әсәрләре өчен дә чыганак булып хезмәт итә («Гасырдан да озынрак көн», «Җәмилә»);

– кыргыз халкы милли рухы, кыргыз әдәбияты колориты үзбәк халкының милли рухына якын булганга күрә, Ч. Айтматов иҗаты үзбәк театрының милли үзенчәлеген үстерүгә дә уңай йогынты ясый;

– язучының әсәрләре режиссёрларның иҗади потенциалын, актёрларның драматик һәм вокал мөмкинлекләрен, сәхнә бизәүче

рәссамнарның һәм башка театр эшлеклеләренең фантазияләрен үстерү өчен бай материал бирә.

**Әдәбият**


1. *Алиева Д.* Эволюция поэтического мира Чингиза Айтматова (категория смерти, категория возраста): дис. ... канд. филол. наук. Ташкент, 1998. 125 с.
2. *Воронов В.* Чингиз Айтматов. М.: Советский писатель, 1976. 231 с.
3. *Захидова Н.* Ташходжа Ходжаев. Ташкент, 1980. 168 с.
4. *Иманкулов Дж.* Ч. Айтматов и советский многонациональный театр: автореф. дис. ... д-ра искусствоведения (17.00.01 – Театральное искусство). Л., 1990. 35 с.
5. *Иманкулов Дж.* Искусство театра: произведения Чингиз Айтматова на сценах театров республик Средней Азии и Казахстана. Фрунзе: Кыргызстан, 1985. 128 с.
6. *Комаха Н.* Образы повести Ч. Айтматова «Материнское поле» в одноименной музыкальной драме Икром Акбарова // Теоретическое музыкознание в Узбекистане: Сб. ст. Ташкент: Изд-во лит. и иск. им Г. Гуляма, 1976. С. 87–101.
7. *Левченко В.* Чингиз Айтматов: Проблемы поэтики, жанра, стиля. М.: Советский писатель, 1983. 232 с.
8. *Раҳматуллаева Д.* Чингиз Айтматов ва ўзбек театри // Чингиз Айтматов ва Ўзбекистон. Хотира китоби. Тошкент: Г. Гулом номидаги нашриет матбааижодий уйи, 2018. Б. 202–215.
9. *Сагитова Г., Хабутдинова М.* Чингиз Айтматов на казанской сцене (на примере татарского академического театра им. Г. Камала) // Филология и культура. 2013. № 2 (32). С. 205–210.
10. *Хурматуллина Р.* Музыкальность как творческий стиль Чингиза Айтматова // Филология и культура. 2013. № 2 (32). С. 281–283.



***Абдурасулов Шохрух Абдунаимович,***
*сәнгать фәннәре буенча философия докторы (PhD),*
*Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Сәнгать белеме институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

***Абдурасулов Шохрух Абдунаимович,***
*доктор философии (PhD) по искусствоведению,*
*старший научный сотрудник Института искусствознания*
*Академии наук Республики Узбекистан*
*abdurasulov.shohruh@mail.ru*